Бала тәрбияләүне ягымлылык, түземлелек, мәрхәмәтлелек, дустанә һәм җылы атмосфера тудырудан башларга кирәк. Баланың яшен искә алып, тәрбияне иҗади рәвештә алып бару зарур, бала күңеленә тәрбия “орлыкларын” көчләп түгел, ә әкият, уен формасында “салырга” кирәк.

Л.Смирнова-Гангнус

# Әти-әниләр белән педагогик эш принциплары.

1. Балаларга белем һәм тәрбия бирүнең актуаль проблемаларына нигезләп, тәрбия һәм белем бирү программасын куллану.
2. Программаның дәвамчанлыгы.
3. Әти-әниләр белән педагогик эшне төрләләндерү (формасы һәм эчтәлеге ягыннан)
4. Әти-әниләрнең шәхси тәҗрибәсен исәпкә алу.
5. Педагогик белем бирү процессында әти-әниләрне туплау, берләштерү.
6. Әти-әниләр һәм балаларга педагогик белем бирү процессында төрле мөмкинлекләрдән файдалану.

# Педагокларның гаилә белән эшләүләрендә гадәти хаталар һәм кимчелекләр.

1) гаилә белән эшләүдә формальлек (гаиләдәге проблемаларга чынбарлыкта игътибар итмиләр, өйрәнмиләр)
2) гаиләнең тәрбияви роленә тиешле бәя бирмәү.
3) әти-әниләр белән уртак тел таба белмәү.

# Балалар бакчасы һәм гаилә бердәмлеге эше тармаклары

1) Балалар бакчасы белән әти-әниләр арасында бәйләнешләр эзләү.
2) Баланың бакчадагы тормышы: беренче көн, беренче атна һәм беренче ай.
3) Әти-әниләр белән хезмәттәшлек: бала тәрбияләүгә карата аларның фикерен тыңлау, бала белән аралашуда кулланган алымнары турында кызыксыну.
4) Гомуми максатка ирешү өчен, хезмәттәшлекне гадиләштерү.
5) Куелаган бурычларныһәм максатларны тормышка ашыру.
6) Педагогик хезмәттәшлекне камилләштерү.